ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.06.2022 г. Казань № 76-10/тэ-2022

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының аерым карарларын гамәлдән чыккан дип тану турында

«КамгэсЗЯБ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә хезмәт күрсәтү буенча эшчәнлекнең җайга салынулы төрен гамәлгә ашыруны туктатуга бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 2022 елның 22 июнендәге 15-ПР номерлы беркетмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының түбәндәге карарларын үз көчен югалткан дип танырга:

«КамгэсЗЯБ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылылык энергиясе (егәрлеге) өчен 2019-2023 елларга тарифлар билгеләү турында» 28.11.2018 № 5-52/тэ;

«Кулланучыларга «КамгэсЗЯБ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан җибәрелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 28.11.2018 № 5-52/тэ карары белән билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2020 ел өчен төзәтмә кертү турында» 13.11.2019 № 5-24/тэ;

«Кулланучыларга «КамгэсЗЯБ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан җибәрелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 28.11.2018 № 5-52/тэ карары белән билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2021 ел өчен төзәтмә кертү турында» 25.11.2020 № 279-47/тэ-2020.

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев